Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге составына керүче Калинин авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге составына керүче Калинин авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 14 апрельдәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: вак таш, асфальт ватык, бетон сатып алу, махсус техника хезмәтләре, Калинино авылында смета-техник документация);

- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру, яктырткычлар сатып алу, монтажлау, баганалар урнаштыру, исәпкә алу приборларын тоташтыру өчен техник шартлар алу, Калинино авылы ял паркында СИП чыбык сатып алу һәм монтажлау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Калинино авылында электр җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру).»

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2024 елның 14 апрельдәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Калинин авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: вак таш, асфальт ватык, бетон сатып алу, махсус техника хезмәтләре, Калинино авылында смета-техник документация);

- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру, яктырткычлар сатып алу, монтажлау, баганалар урнаштыру, исәпкә алу приборларын тоташтыру өчен техник шартлар алу, Калинино авылы ял паркында СИП чыбык сатып алу һәм монтажлау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Калинино авылында электр җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру).»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Мәләкәс авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев